# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлегенең Шыгай авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 19 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Шыгай авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Шыгай авылы торак пунктында “I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Шыгай авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Шыгай авылында (Сабантуй, 9 Май, Яңа ел, өлкәннәр көне, инвалидлар көне) бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- Шыгай авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Шыгай авылында Елга урамы буенча авыл эчендәге һәм зиратка илтүче юлларны ремонтлау (таш ташу һәм вак таш җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Шыгай авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- бензин чапкычлары, ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен отвал һәм запас частьләр сатып алу:

3. Әлеге карарны Азалак авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче: И.Г.Габдулгазизов